КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2024 ел, 23 октябрь

г.Казань

№ 910

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметү буенча төбәк программасын раслау турында» 2023 ел, 30 июнь, 771 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметү буенча төбәк программасын раслау турында» 2023 ел, 30 июнь, 771 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында хәерчелек чигеннән түбәнрәк керемле халык өлешен киметү буенча төбәк программасында (алга таба – Программа):

Программаның II бүлегендә:

егерме сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшь буынны социаль, шул исәптән хезмәт, җайлаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 09 август, 553 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасында (алга таба - Дәүләт программасы), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең төбәк

программасын раслау турында» 2024 ел, 08 июль, 532 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы яшьләрен эш белән тәэмин итүгә ярдәм итүнең төбәк программасында каралган чаралар кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру мәсьәләләрен хәл итүдә аерым урын «Инвалидларны эшкә алу һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвалидларны эшкә алу һәм инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлау өчен эш урыннары квоталау бирелә.»;

«Татарстан Республикасында аз керемле гаиләләр саны (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча)» таблицасыннан соң:

тугызынчы абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«2023 елның 1 гыйнварыннан 17 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле айлык пособие бирелә («Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 ноябрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә).»;

егерменче абзацта «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

Программага 3 нчы кушымтада:

1.6 пунктның 3 графасының дүртенче абзацында «дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 пунктның 3 графасының икенче абзацында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 пунктның 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

1.10 пунктта:

«Гражданнарның аерым категорияләрен (балалар тәрбияләүче хатын-кызларны; инвалидларны; өлкән буын затларны) эш белән тәэмин итүгә ярдәм:» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган инвалидларны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри ориентациясен оештыру» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү, башка җирлектә укытуны да кертеп» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«эшсез гражданнарга психологик ярдәм» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга;

«туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарны профильләү буенча махсус чаралар оештыру һәм уздыру» юлының 3 графасында «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасының» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасының» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин